**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе Урманасты Шынталысы төп гомуми белем бирү мәктәбе**

# Летопись
# “История пионерской организации села Подлесная Шентала Алексеевского района Республики Татарстан”

# “Татарстан Республикасы Алексеевск районы Урманасты Шынталысы төп гомуми белем бирү мәктәбе пионер оешмасы тарихы”

**Эшне башкардылар: 8-9сыйныф укучылары**
**Җитәкче: Миндубаева Нәзирә Х.**

**2017**

Безнең максат һәм бурычлар:

Пионер оешмалары тарихы турындагы белемнәрне арттыру.

Безнең мәктәптә элегрәк пионер оешмасы эшчәнлеге ничегрәк оештырылуы турында мәгълүмат туплау, авылыбызның беренче пионерлары, пионервожатыйлары, балачагы пионер оешмасы белән бәйле шәхесләр белән очрашу.

Бөтенсоюз пионер лагере «Артек», Бөтенроссия пионерлагере «Орленок» турында булган белемнәрне тирәнәйтү, бу лагерьларда ял итүчеләрне барлау, алар белән очрашу.

Мөстәкыйльлекне һәм җаваплылыкны арттыру.

Гражданлык- патриотик хисне үстерү.

Балалар һәм пионер җырларын популярлаштыру.

Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау.

Урманасты Шынталысы төп гомуми белем бирү мәктәбе пионер оешмасы тарихы төрле елларда пионер булган әби-бабайлар, әти-әниләр, абый-апалар сөйләгәннәргә нигезләнеп төзелде.

Эзләнү эшенең планы

1.Пионериянең юлы данлыклы.

2.Урманасты Шынталысы авылында пионер оешмасы барлыкка килү тарихы.
(Беренче пионерлар, төрле елларда пионер оешмасында тәрбияләнүчеләр белән очрашу)

3.Беренче пионервожатыйлар (төрле елларда пионервожатый булып эшләүчеләр белән очрашу)

4.”Артек”, “Орленок” лагерьлары. Анда ял итүчеләр белән очрашу.

5.Урманасты Шынталысы пионерлары “Дубок”, “Березка” лагерьларында ял итәләр.

6. Дружина сборыннан истәлекләр.

7. Юрий Алексеевич Гагарин иемендәге дружинаның пионер отрядлары(әби-бабайларның, әти-әниләрнең, укытучыларның шәхси архивыннан истәлекләр)

8. Урманасты Шынталысы мәктәбенең пионер отрядлары

9. Эзләнү эшенең нәтиҗәсе.

Пионериянең юлы чыннан да данлыклы. Пионер кайда гына булмасын, ул- һәрвакыт беренче. Без дә, әлеге данлыклы оешманың дәвамчылары буларак, аның үткәнен белергә, аның белән горурланырга тиешбез.

*Татарстан…*

*Синең тарихыңны*

***актарам да карыйм…***

***узган еллар агышында***

***Танышларны барлыйм.***

***Шул еллардан килгән отрядлардан***

***Килә алмаш һаман.***

***Еллар үзгә…***

***Ләкин…***

***Балаларга ярдәм кирәк һаман.***

***Варислардан варисларга күчсен…***

***Гасырлардан күчсен гасырга.***

***Изге мирас- туган җирне, телне***

***Без сакларга  тиеш, сакларга!***

## Пионериянең юлы данлыклы



**Эльмира.** Пионер - беренче дигән сүз. Яңа җирләргә беренче булып аяк баскан, шунда төпләнеп калган кешеләрне пионер дип атаганнар. Пионерлар -билгесезлеккә юл салучылар, курку белми, алдан баручылар.
**Аида.** 1922 елның 12 февралендә Мәскәүдә Кызыл Преснядагы типографиянең бер цехына 50 ләп бала җыела. Алар уйныйлар, җырлыйлар, барабан тавышлары астында Мәскәү урамнары буйлап горур атлап үтәләр. Бу иң беренче отрядларның берсе була.
**Эльмира. 1922 елның 19 маенда** комсомолның II Бөтенроссия конференциясе карар бирә: Мәскәүлеләр үрнәгендә һәркайда пионер отрядлары оештырырга. Бу көн пионер оешмасы туган көн булып санала.

- 1923 ел. Мәскәүнең Хамовник районында илебездә иң беренче тапкыр пионерлар йорты ачыла.
-1923 ел. Пионер отрядлары каршында октябрят группалары оеша.
-1923 ел. Март. Беренче пионер журналы «Барабан» чыга башлый.
**Аида.**Тарихтан ишетеп белүебезчә, 1922 елда Татарстанда ачлык була. Бу елларда иң зур проблемаларынң берсе булып ятим, караучысыз балаларның артуы тора. Шунлыктан, Татарстанда 1923 елның июнендә комсомоллар ***Иосиф Малкин һәм Шәһид Шаммазов*** балалар китапханәсендә беренче пионер отрядларын оештыралар.
**Эльмира.** Беренче отрядта 5 звено, анда 49 пионер була. Бу вакытта галстук дигән сүз бөтенләй кулланылмый, кибетләрдә дә галстуклар булмый. Ул вакытта галстукларны сатып алырга акча да булмый. *Беренче пионер отрядын оештыручы Иосиф Малкин бу еллар турында менә нинди истәлекләр язган*: ***" Пионерларга тагарга галстуклар юк иде. Әмма без лозунглар язылган иске кызыл материалны үтүкләп, галстук итеп тактык. Беренче тантаналы линейка урман аланында булды. Пионерлар анда тантаналы вәгъдә бирделәр, ә вожатыйлар аларның һәркайсына галстуклар бәйләделәр. Линейкадан соң отрядлар нык басып, революцион җырлар җырлап, шәһәргә юнәлделәр."***
**Аида.** Менә ул галстуклар. Уйлап карыйк әле, ни өчен галстукларөчпочмаклы формада булган?
Чөнки өчпочмакның өч почмагы өч буынны күрсәткән: коммунист, комсомол һәм пионер берлеген һәм бердәмлеген күрсәткән.
**Бу 1923 елның 5 июле була.** Бу көнне Казанда 2 отрядның 70 пионеры үзләренең ышанычларын революция эшенә багышлап, демонстрациягәчыгалар. Бу кечкенә генә демонстрация зур пионер хәрәкәте башлануның төп сәбәпчесе була һәм Казанда яшәүчеләрдә зур тәэсирләр калдыра. Әлеге көн, дөрестән дә, **Татарстан пионериясенең туган көне** дип билгеләнгән. Шул ук елның август аенда өченче пионер отряды оеша. Шулай итеп пионер отрядлары артканнан арта.
**Эльмира.**1923 елның 18 декабрендә Казанда яшь пионерларның беренче конференциясе була. Әлеге конференция Германиядәге ач балаларга ярдәм итү өчен карар кабул итә. 1924 елдан пионер отрядлары Татарстанның Бөгелмә, Мамадыш, Кукмара һәм башка шәһәрләрендә барлыкка килә башлый. Пионер оешмаларында вожатыйлар җитешми. Шунлыктан Иосиф Малкин һәм В.Дьяконов вожатыйлар әзерли торган ике атналык курслар оештыралар.
**Аида.**-1924 ел. Январь. Бөтенсоюз пионер оешмасына В.И. Ленин исеме бирелә.
-1924 Апрель «Пионер» журналының беренче номеры чыга.
-1924 ел 23 май . Мәскәүнең Кызыл мәйданында пионер оешмасына В.И. Ленин исемебирелүгә багышланган беренче пионер парады була.
- 1925 ел. 6 март «Пионерская правда »газетасының беренче саны чыга.
- 1925 ел. 16 июнь Бөтенсоюз пионер лагере «Артек» оеша.
-1927 ел Кызыл Пресняда балалар өчен беренче тапкыр хәрби спорт пионер уены оештырыла.
- 1929 ел 18-25 август пионерларның 1 нче Бөтенсоюз слеты уза.
**Эльмира.**-1932 ел завод- фабрикаларның комсомол ячейкаларыннан пионер отрядлары һәм дружиналары мәктәпләргә күчә.
-1935 ел. ВЛКСМ ның ҮК бюросы карары белән мәктәпләрдә өлкән пионер вожатый вазифасы кертелә.
**Аида.**-1940 ел Тимурчылык хәрәкәте башлануга этәргеч булып, А. Гайдарның «Тимур һәм аның командасы» дигән китабы дөнья күрә.
-1945 ел Бөртенсоюз пионер оешмасының мактау китабы ачыла.
**Эльмира.**-1959-1960 еллар «Ленинча яшәргә, эшләргә өйрән!» дигән девиз астында пионер дружиналарының Бөтенсоюз смотры уза.
-1956-1957 еллар. Пионер экспедициясе уза.
-1956-1957 еллар Ленинград пионерлары инициативасы белән Кызыл эзтабарлар отряды оеша.
**Аида.**- 1960 ел июнь Бөтенроссия пионерлагере «Орленок» ачыла.
- 1960 ел 20 октябрь пионер икееллыгына старт бирелә.
- 1962 ел 18 май Бөтенсоюз пионер оешмасы Ленин ордены белән бүләкләнә.
- 1962 ел Август. «Артекта» пионерларның 2 нче Бөтенсоюз слеты уза.

- 1967 ел. Севастопальдә пионерларның Бөтенсоюз хәрби- спорт уены «Аҗаган» ( Зарницага ) старт бирелә.
- 1964-1967 еллар «Ленин йолдызлары, балкыгыз!» дигән девиз астында пионер дружиналарының Бөтенсоюз смотры үткәрелә.
- 1967 елның июль- август айларында 3 нче Бөтенсоюз слетына нәтиҗә ясала.
-1967-1970 еллар В.И. Ленинның 100 еллыгына багышлап, «Ленин васыятьләренә тугры без!» дигән Бөтенсоюз экскурсиясе уза.
**Эльмира.**- 1970 ел 29 июнь-3 июль Ленинград пионерларың 4 Бөтенсоюз слеты үтә.
- 1972 ел 17 май Бөтенсоюз пионер оешмасы икенче Ленин ордены белән бүләкләнә.
- 1972 ел 29 май – 4 август. «Артекта» пионерларның Бөтенсоюз слеты уза.
- 1972 ел «һәрвакыт әзер!» Бөтенсоюз маршына старт бирелә.
- 1976 ел 1- 4 август. Пионерларның VI Бөтенсоюз слеты була.
- 1976 ел 17 май. Пионер вожатыйларның бөтенсоюз слеты
- 1976 ел 11- 14 август. Пионерларның VII Бөтенсоюз слеты була.
- 1979 ел . «Илебез пионерлары Ленин эшенә тугры» дигән Бөтенсоюз пионер маршына старт бирелә.
**Аида.-** 1981 ел 18-21 май Мәскәү пионерларының 8 нче Бөтенсоюз слеты ачыла. «Пионер даны» операциясе башлана.
-1982-1986 еллар яшьленинчыларның Бөтенсоюз маршы үтә.
1989 еллар- Пионерларның 9 нчы Бөтенсоюз пионер слеты булып уза.

**1990 елның 15 сентябрендә Артекта булып узган 10 Бөтенсоюз слетында Бөтенсоюз пионер оешмасы бетерелү һәм балалар оешмалары федерациясе төзелү турында карар кабул ителә.**

Безнең мәктәптә дә элегрәк пионер оешмасы эшчәнлеге ничегрәк оештырылды, нилар эшләнелде икән соң?

Шушы сорауларга җавап табу максатыннан без авылыбызның беренче пионерлары белән, балачагы пионер оешмасы белән бәйле шәхесләр белән очраштык. Урманасты Шынтал мәктәбендә шул елларда эшләгән вожатыйлар турында белдек.

19 май пионерлар оешмасы барлыкка килгән көн буларак тарихка кереп калган. Ул чор күптән артта калды. Хәзерге буын ул заман яшьләреннән шактый аерыла, алар коммунизм төзү уйлары белән янмый. Ә менә заманында октябрят, пионер һәм комсомол оешмаларында торган өлкәннәрнең күңелендә моңа бәйле чиксез күп якты хатирәләр сакланган, тормышларында онытылмас эз калдырган.

## Өлкән буын халкы кызыл галстук тагып йөргән балачакларын яратып, горурланып искә алалар.

Илдә барган үзгәрешләр балалар белән эшләү процессында да чагыла.1924-1925 елларда зур шәһәрләрдә балалар оешмалары барлыкка килә башлый. Бу хәбәр 1932-33 елларда шәһәрләрдән читтә урнашкан Урманасты Шынталысына да килеп җитә һәм шушы уку елында беренче пионер оешмасы барлыкка килә. Бу истәлекле вакыйганың ничек булуы турында, ул көннәрнең шаһиты, беренче булып пионерга кабул ителүчеләрнең берсе, Бөек Ватан сугышы ветераны **Бәширов Шәйхулла абый** истәлекләре белән таныштык.(Истәлекләр белән аның туганы таныштырды. Ул 2016 нчы елда бакыйлыкка күчте)Ул 1924 нче елда туган. Бөек Ватан сугышында катнашкан. Авылда колхоз председателе булып эшләгән.



Ул пионер булуы турында менә нәрсәләр язып калдырган:
“”...1933 елда безне Абзалова Халимә дигән укытучы өченче класста укыта иде. Беркөнне ул совет мәктәпләрендә укучы дистә меңләгән балаларның пионер отрядлары сафларында тәрбияләнүләрен, пионерларның кемнәр булуын, пионер оешмасының структурасын сөйләп аңлатты. Пионерларның аерымлык билгеләре, атрибутлары белән таныштырды һәм безнең дә пионер була алуыбыз турында әйтте. Шул көннән башлап без пионерга керү турында хыяллана башладык. Ул, пионер булу өчен укучы һәр эштә һәм һәр җирдә үзен башкаларга үрнәк булырлык итеп тотарга, тырышып укырга кирәклеген әйтә килде. Пионерларның тантаналы вәгъдәләрен һәм пионерлар маршын өйрәтте. Озак та үтмәде, без пионерларның тантаналы вәгъдәсен укып пионер булдык. Муеннарыбызгакызыл галстук тактылар. Ул кызыл материядән эшләнгән иде. Шул минутта Халимә апабыз безне пионер булуыбыз белән котлады. Халимә апаның муенына да кызыл галстук тагылган иде. Шул көннән башлап бездә укуга һәм файдалы хезмәткә дәрт кабынды.”

Менә алар – авылыбызның беренче пионерлары:

1.Бәширов Шәйхулла
2.Вафин Сәгыйть
3.Исламов Касыйм
4.Кузьмин Иван
5.Билалова Галия.
6.Яруллина Әзекәр
7.Х. Шакир
8.Вәлиев Вагиз
9.Вәлиева Галия
10.Ахметова Галия
11.Шәйхетдинов Зыятдин
12.Вәлиев Азат
13.Махмутов Мансур
14.Махмутов Сабир

Пионерлар кызыл галстук, ак күлмәк киеп башка укучылардан аерылып торалар, алар акрынлап башка укучыларны да үзләренә ияртәләр. Пионер оешмасы мәктәпнең җитәкче органына әйләнә.Бу укучылар мәктәп тормышында гына түгел, авыл халкы арасында да иң актив, иң тырыш, тәртипле укучылар булалар. Бу чорда бара торган үзгәрешләрдә үзләреннән булдыра алган кадәр зур өлеш кертәләр: халыкны укырга-язарга өйрәтү, ачыккан гаиләләргә ярдәм оештыру, ялгыз карчыкларга ярдәм итү – бу әле беренче пионерлар эшләгән эшләрнең кайберләре генә.

**Бөек Ватан сугышы ветераны Вәлиев Вагиз Минвәли улы** (1924 нче елда туган) сөйли



Безнең авылда пионер отрядлары 1933 – 1934 нче елларда оеша башлады Безне , беренче пионерларны, “авылыбыз карлыгачлары“ дип йөртәләр иде. Бу чорда пионерважатый булып Абзалова Халимә апа эшләде. Укытучылардан Халилов Хабип абый, Ильин, Ильина Евдокия, Хакимов Фатих абыйлар зур көч куеп эшләделәр .

Каян алганымны хәтерләмим, ләкин галстугым бар иде. Пионер тормышыннан бигрәк тә өмәләр, бәйрәмнәр истә калган. Кияргә кием булмаса да, җырлап яшәдек. Хезмәтне онытмадык”.

Урманасты Шынталы мәктәбенең беренче пионерларыннан берсе 1924 нче елда туган **Билалова(Бәширова) Галия апа** сөйләвеннән.*(Музей материалларыннан алынды. Галия апа 2015 елда бакыйлыкка күчкән)*

- *Мин 1933 нче елда пионер сафларына кабул ителдем. Бу елларда пионер* оешмасы яңа оешып килә иде. Безнең мәктәпнең үзенең кечкенә байрагы һәм барабаны бар иде. Галстук таккан көн хәтеремдә иң тантаналы көннәрнең берсе булып калды. Галстукны кызыл материядән үзебез ясадык. Кайбер балаларның эти-әниләре галстук тагуны тыйдылар. Алар өйләренә кайтканда галстукларын яшереп куя торган булдылар.
Мин отрядта звено вожатые булдым. Үзенә күрә планнар төзеп, эшне тырышып оештыра идем. Бәйрәм көннәрендә урамнан җырлар җырлап үтә идек. Колхозга концерт куярга бара идек. Укытучылар җитешмәгәнгә күрәдер, безгә вожатыйлар булып эшләргә туры килде.


**Галиева (Ярullина)Шәһидә сөйли:** (1927 нче елда туган)

«3 нче сыйныфта укыганда пионер булдым. Галстукларыбыз кызыл материядән иде. Пионерга керү зур тантана, бәйрәм булды. Галстукларны җәй көне дә салмадык. Авылда наданлыкны бетерүгә катнаштык, зурларны укыттык.

Аннан соң менә нәрсә хәтеремдә калган. Ударник булган өчен 3 класста 3м ситса беләнбүләкләделәр. Вәлиев Шәүкәт һәм мин укытучыбыз Камалова Саимә апа белән яхшы укыган өчен Александровка авылы янындагы лагерьга ял итәргә бардык. Ул пионервожатый булып барды. Лагерьда балалар яңа уку елына көч җыйдылар. Балалар да, ата-аналар да бик канәгать булдылар. Шул елларда авылга беренче машина кайтты.Пионерлар байраклар, быргы, барабаннар белән урамны шаулатып йөрделәр. яхшы укучыларны утыртып урам әйләндерделәр.М. Наил, М. Зәкия, В. Рәшидәләр дә яхшы укыйлар иде.”

Күңелендә уелып калган хатирәләрдә Шәһидә апа ул елларны бик еш искә ала. Хәзерге чор балаларга бик яхшы булуын искәртә. Бары тик аларга шәфкатьлелек, миһербанлылык хисләрен жуймаска киңәш итә.Дөньялар тыныч, имин булуын теләп кала.

Безне хезмәт ветераны **Нургатин Закир абый (1931-2015) истәлекләре белән улы Нургатин И.З. таныштырды.**



... “Балачагым авыр сугыш елларына туры килде. Авылдагы бөтен авыр эш безнең җилкәгә төште. Авыр булса да түздек, сынмадык-сыгылмадык. Мәктәптә яхшы укырга да, колхоз, җәмәгать эшенә дә өлгердек.

Пионерга 3нче класста укыганда алдылар. Барысы алдында тантаналы ант биреп, без пионерлар сафына бастык. һәрчак әлеге антка тугры, пионер исеменә лаек булырга тырыштык.Без класста 32 бала идек.Мин Ахметзянов Марс, Галиева Рахилә, Насыров Марс, Ислямов Минхаж, Галиева Сагидәләр белән бергә укыдым.

Безнең мәктәптә укыткан укытучылардан истә калганнары :

-Ильина Евдокия(Бахта)

-Мөнирә апа( Мораса)

-Вәсимә (Адәм Суы)

-Сәлимгәрәева Әлфия(Адәм суы)


-Ермолаева Анна (Кр. Баран)

-Журавлева Анна(Бахта)

-Кольцов

Көл жыю, ялгызы яшәгән әби-бабайларга ярдәм итү, колхоз ындырында эшләү, теге яки бу бәйрәм уңаеннан концерт кую — бу җәмәгать эшләренең берсеннән дә читтә калмадык. Фронтка посылкалар җибәрү дә хәтердә. Туган илебез азатлыгы хакына көрәшкән солдатларга кош теледәй сәламебезне, әниләребез бәйләгән оекбаш-бияләйләрне җибәрү безнең өчен олы горурлык булды. Менә шундый булды ул безнең балачак

## Мубаракшина Халидә апа сөйләгәннәрдән (1941 елда туган)



Пионерлыкның тискәре ягын белмим, хәтерләмим. Балаларны тәрбияләүдә бу оешманың өлеше зур булган дип уйлыйм. Өлкән кешеләрнең кайсыннан сорасаң да, минемчә, тәнкыйтьләмәсләр. Сугыштан соңгы авыр елларда ул балалар тормышына бер ямь, җылылык кертә, бердәмлек, дуслык хисе уята иде. Сборлар, артта калган укучыларга ярдәм итү, өмәләргә йөрү, урак өстендә ярыша-ярыша башак җыю, утауга йөрү, өлкәннәргә, мохтаҗ картларга булышу, авыруларга ярдәм күрсәтү, концертларда, мәктәптә кичәләрдә катнашу һ.б. Болар барысы да мораль канәгатьлек хисе тудыра иде. Һәр буынның үзенә генә хас үзенчәлекләре була инде. Менә безнең буынның балачагы пионерия белән бәйле.

## Галиева Гөлсирин апа (1944 елда туган) сөйләгәннәрдән

***(музей материалларыннан алынды.Ул 2016 елда безнең арадан китте)***

Без бала чакта  9 яшь тулгач – өченче сыйныф – 22 апрельдә, бөтен дружина сборында тантаналы рәвештә пионерга кабул итү церемониясе уза иде.

Май аенда тагын бер бәйрәмне– пионерлар көнен билгеләп үтә идек. 19 майда бөтен укучылар белән Пионер аланына экскурсиягә бара идек. Анда учаклар ягып, уеннар уйнап, рәхәтләнеп күңел ачып кайта идек.

Нык безнең адым, йөрәкләр кайнар. Бу юллар — элек пионерлар яратып җырлый торган тимурчылар җырыннан.Мәктәптә тимурчылар отряды эшли иде. Уку елы башында ярдәмгә мохтаҗларның исемлеге төзелеп, аларга пионерлар һәм комсомоллар беркетелә. Мактау һәм бүләк өмет итмичә, үзебез дә куанып, кешеләрне дә шатландырып, тыйнак кына, тыныч кына эшли идек.

## Гимадиева Физа апа сөйли.

***(музей материалларыннан алынды.Ул 2016 елда безнең арадан китте)***

1941 нче елда туган. Урманасты Шынталы мәктәбендә башлангыч класс укытучысы булып эшләгән.

Моннан 15-20 еллар элек кенә дә башлангыч сыйныфларда укучылар түшләренә яшь Володя (Ленин) сурәте төшерелгән бишпочмаклы кызыл йолдызчык беркетеп октябрят, тагын берничә елдан өчпочмаклы кызыл галстук тагып пионер, өлкәнрәк сыйныфларда комсомол булып горурланып йөриләр иде әле. Хәер, без барыбыз да – бүгенге яшьләрнең әти-әниләре, әби-бабалары үз вакытында шушы әхлак, тәртип, туган илгә бирелгәнлек тәрбияләү мәктәбе аша уздык.

Мәктәптә һәрбер пионер отряды берәр шәхес исеме белән йөртелә иде.

Отряд тагын берничә звенога бүленә. Һәр звеноның кабат үз командиры бар.Звенода һәркемнең үз вазифасы: кемдер чисталык буенча җаваплы, кемдер өй эшләрен тикшерә,икенче берәү тимурчыларэше өчен җавап бирә, стена газетасычыгара һ.б.Звено җитәкчесе отряд командирына отчет-хисапбиреп бара, ай саен сбор, ягъни җыелыш үткәрелә, анда эшләгән эшләргә нәтиҗә ясала, тәртипсезләр "утлы табага" бастырыла. Отряд командиры исә үз чиратында хисапны дружина советы рәисенә биреп бара. Тәртип һәм контроль көчле! Хәзерге укучылар нәрсәгә буйсына?

## **Титова Гөлнур апа сөйләгәннәрдән(**1952елда туган)

Пионер оешмасына керүем 1961 елда булды. Пионер эшендә шефлык юнәлешенә зур игътибар бирелә иде. Әби-бабайларның өйләрен җыештырып, утын кертеп, чишмәдән су алып кайтып, кар көрәп аларга ярдәм итә идек. Эшләр беткәч, шунда ук бергәләп җырлап-биеп кечкенә генә “концерт “ та куеп кайта идек. Бәйрәмнәрдә котлау открыткалары эшләп тапшырдык. Мондый эшләр балаларны мәрхәмәтле булырга, хезмәт сөяргә өйрәткәндер дип саныйм мин. Буш вакытны файдалы итеп үткәрергә дә булышкандыр. Безне ул елларда вожатый туплады. “4”һәм “5” билгеләренә генә укучыларны , актив булганнарны җәй көне пионер лагерена , слетка алып баралар иде**.**

## **Нургатина Дилә сөйли**(1960 нчы елда туган). **Авыл китапханәсендә эшли.**



Укучылар, без дә нәкъ сезнең кебек балалар оешмасы членнары идек. Без ул вакытта октябрятлар һәм пионерлар дип атала идек. Хәзер бу исемнәр эзтабарлар һәм варислар исеме белән алышынды. Ләкин аларның эш юнәлешләре , максатлары бертөрле. Ул вакытта дружина, отряд исемнәре герой-пионер һәм комсомол исемнәре белән атала иде. Мин сезгә шулар турында сөйлим әле.

Бөек Ватан сугышында өлкәннәр белән беррәттән балалар да катнашты. Аларның күбесе разведчик һәм диверсант сыйфатында я чын сугышта, я партизан отрядларында хәрәкәт иттеләр. Алар пионерлар һәм комсомоллар иде.

Сугышның беренче көннәреннән үк Брест крепостен саклауда музыка взводы тәрбияләнүчесе 14 яшьлек Петя Клыпа аерылып торган. Иң яшь партизаннардан Марат Казей, Володя Дубинин, Леня Голиков һәмВаля Котик күп батырлыклар эшләгәннәр. Алар дүртесе дә Советлар Союзы Герое исеменә лаек булганнар. Мәсәлән, Леня Голиков 1943 елның 24 январенда Дедовичевский районы Острая Лука авылында немецлар белән хәлиткеч сугышта һәлак була. Бу авылда Леня Голиков каберенә обелиск куелган, ә Пола елгасы буенда һәйкәл салынган. 1960 елда Мәскәүдә дә Л. Голиковка һәйкәл куелган. Леня Голиков исеме В.И.Ленин исемендәге Бөтенсоюз пионер оешмасының Почет Китабына кертелгән. Аңа Советлар Союзы Герое исеме үлгәннән соң бирелгән.

Сугышчан батырлыклары өчен уннарча мең пионер һәм комсомол орден һәм медальләр белән бүләкләнгәннәр:

- Ленин ордены белән - Толя Шумов, Витя Коробков, Володя Казначеев;
- Кызыл Байрак ордены белән - Володя Дубинин, Юлий Кантемиров, Андрей Макарихин, Костя Кравчук;
- Беренче дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән - Петя Клыпа, Валерий Волков, Саша Ковалев;
- Кызыл Йолдыз ордены белән - Володя Саморуха, Шура Ефремов, Ваня Андрианов, Витя Коваленко, Леня Анкинович;
- Йөзләрчә пионер “Бөек Ватан сугышы партизанына”, 15 меңнән артыгы “Ленинград оборонасы өчен”, 20 меңнән артыгы “Мәскәү оборонасы өчен” медальләре белән бүләкләнгәннәр.

Күп кенә яшьләр хәлиткеч сугышларда һәлак булганнар, шактыен немецлар җәзалап үтергән. Бу балалар барысы да В.И.Ленин исемендәге Бөтенсоюз пионер оешмасының Почет Китабына кертелгән һәм алар геройпионерлар исеме белән йөртелә башлаганнар.

Менә алар: Леня Голиков, Марат Казей, Лида Матвеева, Саша Ковалев, Валерий Волков, Зина Портнова, Вася Коробко, Нина Сагайдак, Володя Дубинин, Саша Бородуллин, Гриша Акопян, Нина Куковерова, Витя Коробков, Валерий Волков, Кычан Джакыпов, Петр Зайченко, Коля Мяготин, Павлик Морозов, Юта Бондаровская, Валя Котик, Камилия Шага, Лара Михеенко, Галя Комлева, Толя Шумов. Аларның батырлыгын без зур хөрмәт белән искә алырга тиешбез.

Мин, үз чиратымда, сезнең шушы герой-пионерлар кебек курку белмәс, Ватанны яратучы патриот булып үсүегезне телим. Акыллы булыгыз, тырышып укыгыз, сәламәт булып үсегез, герой-пионерлар шикелле Ватанны яратыгыз.

## Миндубаева Нәзирә Хәсән кызы сөйләгәннәрдән: (1962 нче елда туган).

### Мәктәптә укытучы булып эшли

“Мин Ю.А. Гагарин исемендәге дружинага 1973 елда кабул ителдем. Әлеге көнгә бик озак әзерләндек. Беренче укытучыбыз Вәлиева Исламия апа Харис кызы белән берлектә пионер законнарын, антны, герой пионерларның тормыш юлын өйрәндек. Менә ул көн килеп җитте. Барыбыз да тантаналы линейкага тезелдек. Безнең уң кулыбыз алга сузылган, аларга кызыл галстуклар эленгән. Галстукларны безгә алдынгы пионерлар бәйләде.

Ә бәйрәмнән соң “мине барыгыз да күрегез” дигәндәй, изүләремне ычкындырып урам буйлап галстугымны күрсәтеп кайтканым истә. Бик зур шатлык иде пионерга кабул ителү.

Шушы ук елдан тагын бер сөенечем хәтердә: яз көне пионерга кабул ителсәм, җәй көне беренче тапкыр Биләрдәге “Имәнкәй” (“Дубок”) пионер лагерена ял итәргә бардым.”

## Ишниязова Энже Хәниф кызы сөйләгәннәрдән. (1971 елда туган)

**Мәктәптә укытучы булып эшли**

“Урманасты Шынталы сигезьеллык мәктәбенең 3 классында укыган вакытта, 1980 елның 22 апрелендә пионер сафларына кабул ителдем. Мәктәпкә бөтенебез дә формадан йөрибез: кызлар көрән-кара күлмәк, ак яки кара алъяпкычтан, җиңнәрдә ак манжет, ак яка, малайлар зәңгәр костюм- чалбардан.Әгәр пионер икәнсең, галстук һәм значок һәрвакытта да булырга тиеш. Дружина Ю.А.Гагарин исемен йөрткәнгә күрә, бу шәхеснең тормышын җентекләп өйрәндек, һәр адымыбыз, эшебез белән аның исеменә тап төшермәскә тырыштык. Төрле кызыклы темаларга отряд сборлары үткәрелде. В.И.Ленинга багышланган альбомнар, стендлар эшләү буенча ярышлар оештырыла иде. Шулай ук кичәләр, концертлар күңелле үтә иде. Хәрби-патриотик тәрбия буенча да эш алып барылды, ел саен дружина “Аҗаган” уенында катнашты.”

## Миндубаева Энже Кыяметдин кызы(1972 елда туган).

**Мәктәп директоры**

Әле кайчак уйланып утырам да, пионер, комсомол оешмаларының уңай яклары күп булган инде ул. Бездә, балаларда, бердәмлек, татулык хисе тәрбияли иде, кайда да беренче булырга омтылып үстек без. Мәктәп — бер дружина, һәр класс — бер отряд иде. Отрядлар арасында һәрчак ярыш рухы булды, бөтен максатыбыз — укуда, җәмәгать эшләрендә алдынгылардан булу. Укулары аксаган иптәшләрне «тарту», ягъни дәрестән соң калып шөгыльләнү дигән нәрсә бар иде. Кыскасы, һәрчак бер-беребезгә ярдәм иттек, бер гаилә кебек тату булып үстек.

“Кем соң ул пионер?” - дигән сорау белән укытучыларыбызга мөрәҗәгать иттек һәм түбәндәге җавапларны алдык?

-Пионер беренче, алдынгы, алдан баручы, дигән сүз. Кешеләр өчен яңалыкка, моңарчы билгеле булмаганга кыю юл салучы, яңалык кертүче, беренче ачыш ясаучы һәм уйлап табучыны бөтен дөньяда пионер диләр

Әхмәтҗанова Җ. З.

-Пионерлар акыллы һәм тырыш балалар булганнар. Алар яхшы укыганнар, олыларны хөрмәт иткәннәр, мәктәпне яратканнар.

Исхакова Л.А.

- Алар походларга йөргәннәр, тимер-томыр җыйганнар, табигатьне саклаганнар, хезмәтне яратканнар.

Махмутова Г.Н.

-Пионер үрнәк башка укучыларга, терәк укытучыга...

Миндубаева А.М.

- Пионер – алда атлаучы, бөтен җирдә беренче ул!

Маткаримов Р.М.

-19 май безнең буын өчен пионер туган көн булып күңелгә кереп калды. Кемнән сорашсаң да, пионер чоры турында яратып сөйләп бирер. Муенына галстук тагучы өлкән класс укучыларының "важныйлыгы", тезләнеп, дружина байрагын үбеп торуның дулкынландыргыч булуы, беренче тапкыр рапорт биргәндә, тез буыннары калтыраган минутлар онытылырлык түгел. Хәзерге балалардан без барыбер бәхетлерәк булганбыз.

Вәлиева И.С.

## "Пионервожатый истәлекләре"

**Урманасты Шынталысы мәктәбендә төрле елларда <u>пионервожатый булып</u> эшләүчеләр:**

***1.Абзалова Халимә -1933***
***2.Камалова Саимә -1936***
***3.Журавлева Анна-***
***4. МаннановаГарифә***
***5. Әлфия***
***6. Гайшә1957-1960***
***7.Вафина Гөлсем 1960-63***
***8. Галлямова Зөлфирә 1963-65***
***9.Ишниязова Рабига 1966-65***
***10. Гатина Саимә1966-69***
***11.Исхакова Сәгадәт 1970-72***
***12.Галиева (Вәлиева )Гөлсимә 1974-1978***
***13 Миндубаева Суфия1978-80***
***14.Хуснутдинова Римма 1980-1982***
***15.Гафиятуллина Фидания1983-1986***
***16.Ишниязова Сирень 1986-1989***
***17. Махмутова Гүзәлия 1989-1990***
***(исемлекне төзүдә Ишниязова Рабига апа ярдәм итте)***

## Беренче пионервожатый- Камалова Саимә



Саимә апа кызы белән. 1981 ел

Саимә апа шат күңелле, тынгысыз иде. Төрле-төрле уеннар, күңел ачулар оештыра иде.Вәлиев Шәүкәт һәм мин укытучыбыз Камалова Саимә апа белән яхшы укыган өчен Александровка авылы янындагы лагерьга ял итәргә бардык. Ул пионервожатый булып барды. (Яруллина Шәһидә сөйләгәннәрдән)




**40 ел балаларга белем һәм тәрбия биргән Ишниязова Рабига апа белән әңгәмә (1945 елда туган)**

***-Рабига апа, Сез — балачакта, яшьлектә пионер, комсомол вәкилләренең матур үрнәге булган кеше, гомер буе шул идеалларга тугры калып, ягъни актив, алдынгы булып, тормышны матурларга, дөньяны яхшыртырга тырышып яшәгәнсез... Хатирәләрегез белән уртаклашмассызмы икән?***

- Ул идеаллар бер дә начарлыкка өйрәтми иде бит,гомеремне укытучы һөнәренә багышладым. Ничә буын укучыларым да, үземнең 5 балам да пионер булды. Аларны Казан, Чистай шәһәрләренә экскурсияләргә алып барганымны, бергәләп «Пионерская правда», «Яшь ленинчы» кебек гәзитләр, "Ялкын" журналын укыганны әле дә булса хәтерлим. Бу басмаларда безнең укучыларның мәктәп тормышындагы кызыклы вакыйгалар турындагы язмалары да басылды. Укуда да сынатмаган, җәмәгать эшләрендә алдынгылар сафында барган пионерларны Кара диңгез буена «Артек» лагерена юллама белән бүләкләү бар иде.Үз кызым Сирень дә бу юлламага лаек булды. Менә бит нинди яхшы гамәлләр!

Шундый яхшы гына эшләп килгән җәмәгать оешмаларын бетерделәр дә куйдылар. Миңа калса, бу ахмаклык. Хәзер менә яшьләрнең яман гадәтләр белән дуслашуына, начар юлга басуына зар елыйбыз. Бөтен нәрсә эшсезлектән, кызыксыну юклыктан килә. Безнең заманда, мәсәлән, эчкечелек, җинаятьчелек турында уйларга да вакыт юк иде. Ә хәзер, мәктәптәге дәресләрдән соң бала урам ирегенә бирелә. Ярый, кайберләренең шөгыле бар — сәнгать, я булмаса спорт мәктәпләренә йөри. Ә бит туры юлдан тайпылганнары да шактый. Менә шуларга карап, йөрәгем әрни. Хәзерге яшь буынга бердәмлек, дуслык, татулык хисләре җитешми. Пионер оешмасын бетердек — ә менє аны алыштырырдай, яхшы башлангычлары булган оешма төзи алмадык. Нигә заман яшьләре бу кадәр тәртипсез икән?! Җәмәгать оешмалары әле дә бар

ул, юк түгел. Ә пионерия оешмасы ул бердәнбер булган, — дип, сөйләде безгә 40 ел балаларга белем һәм тәрбия биргән Рабига апа Ишниязова.

Балаларны бик ярата шул ул. Бүген дә тормышын аларсыз күз алдына китерә алмый. Әле дә ул алар арасында. Инде үз оныклары үсеп җитеп килә, ә Рабига апага алар гына җитми. Ул очрашуларга, кичәләргә бик теләп йөри, эзләнә, үткән тормыш турында истәлекләр туплый, алар хакында бүгенге буынга сөйләп калырга, яшьләрдә миһербанлылык, әдәп-тәртип тәрбияләргә омтыла.

Рабига Вәли кызы гомере буе җәмәгать эшләрендә дә кайнап яши. Ветераннар советы рәисе булып та эшли, авыл сәхнәсеннән дә төшми.

Ишниязова Рабига апаның шәхси архивыннан алынган истәлекләр


***1***

***1960 ел. Ишниязова Рабига***



Ишниязова Рабига, Вәсимә.Урманасты Шынталы мәктәбендә эшли башлаган еллар.

| | |
|---|---|
| <br>***1976 ел, Ишниязов Илсур*** | <br>Е<br>Ишниязова<br>***1976. Ишниязова Сирень*** |
| 1980 ел. И.Инсаф-пионер, И.Илназ-1 класс укучысы |  |
| 1984 ел. И. Фәнүс. Мин дә апам һәм абыйларым кебек пионер булдым. | <br> |



7 класс укучысы Ишниязов Идрис Солтан улы һәм 6 класс укучысы Ишниязов Илназ Фәрдус улы. 3 нче класс укучыларын пионер сафларына кабул итү сборыннан соң.

## Вәлиева Гөлсимә Камил кызы



**Вәлиева Гөлсимә Камил кызы** 1955 елның 1 нче июнендә Алексеевск районы Урманасты Шынталы авылында туа.1962 елда беренче класска укырга керә. 1970 елда сигезьеллык мәктәпне уңышлы тәмамлап, Арча педагогия училищесына укырга керә. Студент тормышында ук ул үзен актив оештыручы буларак таныта. Җәйге каникул вакытында пионер лагерында вожатый булып эшли. Һәр көнне эшенә яратып әзерләнеп килгән вожатыйны балалар бик тиз үз итәләр.

**Вәлиева (Галиева) Гөлсимә апа сөйләгәннәрдән.**

**...** Өченче класста укыганда мин пионер булдым. 1964нче елның 22нче апреле. Советлар Союзы пионерының тантаналы вәгъдәсен мин дә бирдем.Советлар Союзы пионерларының Законнарын мин дә өйрәндем һәм үтәдем.

33 еллык эш стажымның баштагы 6 елында мин өлкән пионервожатый булып эшләдем. Бу эш елларымны бик сагынып искә алам. Ул вакытларда мин 20 яшьлек кыз бала идем. Үзебезнең мәктәпнең пионерлары белән бик күңелле, файдалы эшләр башкардык.

Мәктәптә Тимур командасы оешты. Авылыбызның әби – бабайларына бик теләп ярдәм итә идек. Һәр бәйрәм саен актив укучыларымны туплап, әдәби –музыкаль монтажлар, концертлар куйдык. Ул чорның пионерлары озын тәнәфесләрдә оештырган җырлы – биюле уеннарны әле дә сагынып искә алалар. Бик яратып чын күңелемнән отряд советы һәм дружина советы председательләре, отряд вожатыйлары, йолдызчык вожатыйлары белән укулар үткәрә идем.

Сагынам мин ул көннәрне һәм ул чорның самими, һәр яңалыкны өйрәнергә, эшләргә, һәрвакыт ярдәм итәргә торган пионерларын. Болар турында сөйләгәндә яшьлегемә кире кайтам. Аларның җырлары колакта әлә дә яңгырап тора. Пионерлар җырлаган җырларны сез дә тыңлагыз әле.

Радостным шагом, с песней веселой.
Мы выступаем за комсомолом.
Близится эра светлых годов.
Клич пионера "Всегда будь готов!".

Юной и смелой, дружной гурьбою.
Будем готовы к труду и бою.
Будем примером борьбы и трудов.
Клич пионера"Всегда будь готов!".

Грянем мы дружно песнь удалую.
За пионеров семью трудовую.
Будем примером борьбы и трудов.
Клич пионера "Всегда будь готов!".

**Пионервожатый булып эшләгән Вәлиева Гөлсимә апаның шәхси архивыннан истәлекләр**



1977 ел. Урманасты Шынталы сигезьеллык мәктәбенең өлкән пионервожатые.
"Бу матур кыз да – мин. Хәзер дәрәҗәсе төшсә дә, безнең өчен. **Пионер галстугы** бик мөһим атрибут иде. Күрәсезме, бу фотода минем бар кыяфәтем  - коммунизм."



1973 ел. Казанның “Молодая гвардия” лагерында пионервожатый булып эшләгән еллар.Сулдан өченче – Вәлиева Гөлсимә



1973 ел. Казанның “Молодая гвардия” лагерында пионервожатый булып эшләгән еллар.



1986 ел. 3 нче сыйныф укучыларын пионерга кабул итү сборы.



1977 ел. 22 апрель. 3 нче сыйныф укучылары пионер булдылар.

Шатлыгыбызны күрсеннәр диеп,
Бөтен урамны шаулатып йөрдек.
Иң истәлеке көнебез бүген-
Без пионерга кабул ителдек.
Инде без зурлар, без- пионерлар!

- Пионер галстугы, ул бизәнү әйбере дә, өс киеме дә түгел. Ул пионер оешмасында торганлыкны аңлата.

Кызыл галстукның беренче пионер отрядларына кадәр үк килеп чыгуын беләсез микән, - дип башлады сүзен мәктәптә пионервожатый булып эшләүче Гөлсимә апа. –Бу болай була: 1919нчы елда беренче май демонстрациясенә олылар белән балалар да чыга. Эшчеләр кулында кызыл флаглар. Ә балаларның муенына, аларның да яңа дөнья төзергә теләүләрен барысы да күрсен дип, кызыл косынка бәйлиләр.

Бүгеннән сез Советлар иленең Дәүләт флагына әверелгән бер кисәген муеныгызда йөртәчәксез. Пионер галстугының өч почмагы – Коммунист, комсомол һәм пионерның какшамас дуслыгы билгесе. Һәрвакыт һәм һәркайда – көндәлек тормышта да, бәйрәмдә дә, мәктәптә, өйдә, урамда да – пионер галстугының кадерен белегез. Муеныңа галстук тактыңмы – аны сакла. Ул кызыл байрак белән бер төстә.



***Галстугым шуңа ал минем***
***Яшь коммунист монда күмелгән,***
***Ирек өчен каны түгелгән.***
***Кара көчләр барыбер җиңелгән,***
***Авылыбызга байрак эленгән –***
***Галстугым шуңа ал минем.***
***Фашист явы килгән ерактан,***
***Егетләрен авылым озаткан.***
***Көч алганнар алар байрактан***
***Кан төсендә азат таң аткан.***
***Галстугым шуңа ал минем.***
***Мәктәп түбәсендә ал комач***
***Җилфер-җилфер килә таң тугач,***
***Галстукка минем тап кунмас.***
***Байрак төсе булып балкыгач –***
***Галстугым шуңа ал минем.***

**Әлеге шигырь юлларын ничәмә-ничә буын пионерлары өйрәнеп үсте.**

# Ишниязова Сирень Фәрдус кызы



**Ишниязова Сирень Фәрдус кызы** 1967 елның 16 нчы сентябрендә Алексеевск районы Урманасты Шынталы авылында туа.1974 елда беренче класска укырга керә.1982 елда сигезьеллык мәктәпне уңышлы тәмамлап, Түбән Кама педагогия училищесына укырга керә.Училищены бик яхшы билгеләренә тәмамлап туган авылы мәктәбенә эшкә кайта. Математика укыту белән бергә, пионервожатый да булып эшли. Ул тиз арада балалар белән уртак тел таба.

**Ишниязова Сирень сөйләгәннәрдән**

***-Пионерга кергән көнегезне хәтерлисезме?***

- Их, кызыл галстуклы ул балачак! Быргы, барабан тавышлары, ялкынлы җырлар, киләчәк турында матур әкиятләр...

Минем балачагым да нәкъ шул чорның матур үрнәге булган пионер, комсомол оешмалары чәчәк аткан вакытка туры килде. Пионерга кергән көнем бүгенгедәй хәтеремдә. Беребездән беребез тырышып тантаналы вәгъдә бирдек, пионер законнарын әйттек, пионерлар турында шигырь юллары сөйләдек. Менә безгә кызыл галстуклар бәйләделәр. Миңа галстукны Вафина Нәзирә бәйләде. Галстук белән фотога да төштем.

Шунысы хәтердә калган: өйгә кайтканда, ярты юлга җиткәч,сумканы җиргә куеп,( 22 апрель бит, җир әле кипмәгән иде) галстугымны куртка өстеннән чыгарып куйдым.

***-Пионервожатый булып эшләгән елларыгыз турында ниләр әйтә аласыз?***

Үзебезнең мәктәпнең пионерлары белән бик күңелле, файдалы эшләр башкардык. Дружина сборы, отряд сборлары үткәрә идек.Сбор – ул җыен дигән сүз. Димәк, отрядның җыелып сөйләшүе, киңәшүе, мероприятие үткәрүе, экскурсия, походка баруы, тематик кичә уздыруы – болар барысы да җыен, ягъни сбор була. Май аенда мәктәптә Пионер сабан туе оештыра идек. «Тамчы» бию түгәрәге оештырдым. Укучылар белән мәктәптә дә, клубта да, хәтта район сәхнәләрендә дә чыгыш ясарга туры килде.

Пионер минем өчен мәңгелек оешма, изгелек, чын фидакарьлек орлыклары тәрбияли торган чиста башлангыч булып калачак.

## Шәхси архивыннан истәлекләр



Пионервожатый булып эшләгән еллар бик тә сагындыра



“Тамчы” бию түгәрәге кызлары: Әхмәдиева Гүзәл һәм Титова Римма





1989 ел. Пионер сабан туеннан күренешләр. Ягез, кем өлгер, кем җитез?



Минем  беренче укучыларым



“Туган якны өйрәнү”
музее җитәкчесе Мустафина Гөлсинә пионерларның атрибутлары –галстук, барабан, быргы, пионер байрагы, пионер формасы турында сөйләде**.**



1922нче елда, пионер оешмасы төзелгәч, күпме балалар пионер булырга хәзерләнгән. 1932-33 елларда Урманасты Шынталысында беренче тапкыр быргы, барабан тавышлары яңгырый. XX гасырның 80нче елларында аларның саны миллионнар белән исәпләнә иде. Пионер формасы, дружина һәм отряд, звено сборлары. Пионер лагере... Болар безнең күңелләрдә балачакның иң матур мизгелләре, мәңге онтылмас хатирәләре булып сакланып калды.

Без яңа тормыш алып киләбез,
Урамнар, безгә юл бирегез!
Барабаннар сугып үтәбез без
Ал байраклар белән, күрегез.
Пионер, алга,
Зур көрәш алда.
Комсомолларга
Салют бирәбез,
Алмашка киләбез.
Мин әнә шундый шигырьләр сөйләп үскән пионерлар токымыннан




Кызыл галстук, Ильич рәсеме төшерелгән значок, дружина байрагы, пионер барабаны, быргысы – барысы да музей экспонатлары булып калды хәзер.

**Галстук**

Пионер галстугының өч чаты бар. Өч тармак һәм бер нык төен. Коммунизм өчен көрәшүче өч буын –коммунистлар, комсомоллар , пионерлар – бер-берсе белән әнә шулай нык бәйләнгән .

Пионер галстугы ,безнең байрагыбыз кебек үк , кызыл төстә, чөнки ул халык бәхете өчен көрәшкән меңнәрчә батыр көрәшчеләр каны сеңгән байракның бер кисәге.

Кызыл галстук беренче пионер отрядларына кадәр үк барлыкка килә.1919 елгы Беренче май демонстрациясенә олылар белән бергә балалар да катнаша.Эшчеләрнең кулларында кызыл флаглар була, ә балалар, яңа тормыш төзүчеләргә алмаш килгәнен барысы да күрсен өчен, муеннарына кызыл косынка бәйлиләр .

Миллионнарча совет кешеләре үз вакытында пионер галстуклары бәйләп йөрделәр, пионер отрядларында Ленин васыятьләрен үтәргә өйрәнделәр.

Муеныңа кызыл галстук бәйләгәнсең икән ,аны сакла, аның кадерен бел .

Чит илләрдәге балалар –пионерлар һәм башка демократик оешма членнары да галстук бәйлиләр. Аларның кайберләренең, мәсәлән, Болгария ,Венгрия, ГДР, Югославия пионерларының галстуклары кызыл төстә. Икенчеләрендә галстук илнең милли флагы төсендә. Мәсәлән, поляк харцерларының галстугы кызыл һәм ак төстә.

**Пионер значогы**

Пионер значогы пионерга кызыл галстук белән бергә тапшырыла.

Значокка В.И. Ленин барельефы төшерелгән . Өч ялкын теле өч буынның : коммунист , комсомол һәм пионерлар буынының какшамас бердәмлелеген чагылдыра.

Значокның лентасындагы : “ Һәрвакыт әзер!” дигән язу пионерларның девизга җавабы. Пионер значогы күкрәкнең сул ягыны тагыла.

Матур уйнагыз, әй быргычылар,
Барабанчылар, тигез кагыгыз!

## ПИОНЕР БАЙРАГЫ

Пионер байрагы – пионерларның намуслылык һәм тупланганлылык, революция, Коммунистлар партиясе, социалистик Ватанга тугрылылык билгесе.

Пионерларның Кызыл байраклары пионер дружинасында , район , шәһәр , республика оешмаларында , В.И.Ленин исемендәге Бөтенсоюз пионер оешмасында була.

Бу байраклар турында төп положениеләр ВЛКСМ Үзәк Комитеты Бюросы

1967елның 22 августында кабул иткән “Пионер дружинасының район, шәһәр, өлкә , край , республика һәм Бөтенсоюз пионер оешмасынын Кызыл байрагы турында”гы карарында әйтелгән.

**Барабан**

Барабан пионер атрибуты булып тора һәм походлар, тантаналар , парадлар вакытында стройны алып бару өчен кулланыла.

Барабан пионер бүлмәсендә отряд флагы янында саклана.

Отряд советы тарафыннан билгеләнә торган барабанчы строй алымнарын башкарырга һәм”Марш “ , “ Дробь» уйныйбелергәтиеш.

Стройда барабанчы быргычының сул ягында торырга тиеш иде .

## БЫРГЫ

Пионер быргысы (фанфара) пионер отряды атрибуты булып санала һәм пионерларгны сборга чакыру , төрле сигналлар бирү өчен һәм ритуаллар вакытында кулланыла иде.

Быргыга чук белән каймаланган һәм пионер значогы төшерелгән кызыл флагчык беркетелә .

Быргы пионер бүлмәсендә отряд флаглары янында саклана иде.

Быргычы пионер отряды тарафыннан билгеләнә, ул быргы белән строй алымнарын башкара . Ул тантаналы сигналларны белергә тиеш .

Пионер линейкасында быргычының урыны –стройның уң флангысында , барабанчы янәшәсендә; лагерь мачтасы янында – йөзе белән стройга карап тора ; отряд колоннасында- флаглар артында ; дружина колоннасында - байракчы артында була

.




Пионер оешмасына кабул ителгәч, дружина байрагы янында фотога төшү безнең мәктәпнең традициясе иде.(Ахметзянова Алсуның пионерга кабул ителгән көне)



Пионер формасы

Пионерларның парад формасы комплекты малайлар өчен билгеләнгән үрнәктәге ак күлмәктән , соргылт- зәнгәр шорттан (яки чалбар) кызлар өчен ак кофта һәм соргылт –зәнгәр юбкадан тора .

Соргылт зәнгәр пилотка һәм махсус металл прәшкәле сары каеш та пионер формасы комплектына керә. Сул җиңдә пионер значогы рәсеме төшерелгән шеврон һәм пионер активының аеру билгеләре беркетелә.

Байрак йөртүчеләр һәм ассистентларның парад формаларында аермалыклар бар: ак баулы кызыл пилотка металл прәшкәле ак каеш, ак перчаткалар һәм уң иң баш аркылы киелә торган сары каймалы кызыл тасма.

Ак каеш һәм ак перчаткалар быргычы һәм барабанчылар формаларында да була

## «Бөтенсоюз пионер лагере “А р т е к”та ял иттем мин ...»

Әнә шулай горурланып сөйлиләр Урманасты Шынталы мәктәбе укучылары Ишниязова Сирень һәм Әхмәдиева Гүзәл.

### «Артек» истәлекәре

Ишниязова Сирень Фәрдус кызының шәхси архивыннан алынды.

**“А р т е к” – дөньядагы барлык балаларның ДУСЛЫК һәм ТУГАНЛЫК, БӘХЕТ һәм ТЫНЫЧЛЫК символы ул!**



Ишниязова Сирень 1967 елның 16 сентябрендә Татарстанның  Алексеевск районы Урманасты Шынтала авылында туа. Туган авылындагы  мәктәпкә укырга бара. Бала чактан ук яшьтәшләре арасында яхшы укуы, бераз олыларчарак холкы-фигыле белән аерылып тора. Чын татарча өлгер һәм зирәк кызны сыйныфташлары да, укытучылар да үз итә. Хикмәт шунда, ундүрт яшьлек Сирень бик яшьли авыл “тарихына эләгә - атаклы “Артек” пионерлагеренда ял итеп кайта.

«1981 ел. Мәктәпнең VI1сыйныфын тәмамладым. Алексеевск районына  бүлеп бирелгән юлламаның миңа эләгүе бик зур шатлык булды. Әтием мине Казанга кадәр озатып куйды. Шунысы хәтердә калган: әнием юлга 1 литрлы банкага май белән бал болгатып җибәргән иде. Поездда барганда шул ризык 5 вожатыйга һәм 40 балага ипигә ягып ашарга җитте.Поезд белән Мәскәүгә бардык. Анда экскурсия булды. Аннан 1980 нче елгы Олимпия аюын сатып алдым. Аннан тагын поезд белән киттек. Шулай итеп, мин илебезнең иң абруйлы пионер лагерена - Артекка барып эләктем. “Кипарисная”да ял иттем. Вожатыебыз Аниса Гаффановна иде.Отрядта мин звеньевая идем.Чаллы кызы Ольга Князева, Казаннан Айрат Бариев белән дуслашып киттек. Шактый еллар хатлар языштык. Төрле чараларда актив катнаштым. Фототүгәрәккә йөрдем. Тагын шунысы истә калган: төрле республикалардан килгән балалар үз республикаларын яклап чыгыш ясарга тиеш иде. Мин татар халык биюен биедем.

Бераз тарихка күз салыйк: 1925 нче елның 16 июнендә АЮ-Даг итәгендәге палаткалар шәһәрчегендә Кызыл байрак күтәрелә. Бу – Бөтенсоюз пионер лагере “Артек”ның ачылуы хөрмәтенә иде.

“А р т е к” – дөньядагы барлык балаларның  ДУСЛЫК һәм ТУГАНЛЫК, БӘХЕТ һәм ТЫНЫЧЛЫК символы ул!

“Артек” хәтта сугыш вакытында да ябылмаган. Бөек Ватан сугышы елларында ул Мәскәү аша Сталинградка, соңрак 1944 елга кадәр Алтайга күчерелә. Балаларның бер өлеше вакытлыча Казанда һәм Уфада да яшәп ала. 1944 елның апрелендә “Артек” территориясе дошманнардан чистартылгач, лагерь тиз арада торгызылып, августта балаларны кабул итә башлый. Күрәсез, ни авыр сугыш елларында да ул балаларны үзенә туплый алган, шул чакларда да илебез балаларны ял иттерү мөмкинлеген тапкан.

1969 елда инде “Артек”ның 150 бинасы, 3 медицина үзәге, мәктәбе, “Артекфильм” студиясе, 3 бассейны, 7000 урынлы стадионы һәм мәйданчыклары була.
Совет елларында безнең илебездә генә түгел, чит илләрдә дә “Артек”ның дәрәҗәсе искиткеч зур иде. “Артек”ның иң популяр чакларында биредә елына 27 000 бала ял иткән. Леонид Брежнев, Юрий Гагарин, Индира Ганди, Никита Хрущев, Джавахарлал Неру,Отто Шмидт, Пальмиро Тольятти, Хо Ши Мин, Бенджамин Спок, Михаил Таль, Валентина Терешкова “Артек”ның почетлы кунаклары була.

Иң мөһиме — “Артек”чы булу өчен әти-әниеңнең калын кесәсе дә, зур урында эшләве дә әһәмиятле түгел иде.»

(Ишниязова Сирень сөйләгәннәрдән)




Икенче рәттә уңнан беренче – Ишниязова Сирень.

***Я знаю - друзья у меня***
***есть повсюду,***
***Под небом огромным***
***в любых уголках...***

***Артек- это радость,***
***Артек- это чудо,***
***Артек – это дружба***
***На всех языках***



Икенче рәттә уңнан беренче Ишниязова Сирень.

## «Артек» истәлекәре

Әхмәдиева (Усманова)Гүзәл Гаваз кызының шәхси архивыннан алынды.



“Унөч яшьләр тирәсендә миңа, ниндидер могҗиза белән, «Артек» пионер лагеренда ял итәргә туры килде. Аюдаг итәгендә, Кара диңгез буенда җәйрәп яткан бу җәннәт почмагында

кемнәр генә, нинди генә милләт балалары юк иде. Безнең дружина үзе генә дә СССРның нәни бер моделен хәтерләтә иде. Эстоннар, литвалылар, латышлар, украиннар, руслар, белоруслар, гөрҗиләр, әрмәннәр, әзәриләр... Төрле конкурс-бәйгеләрдә катнашып кечкенә бүләк алуыма кош тоткандай сөенеп бик канәгать кайттым лагерьдан.”(Әхмәдиева Гүзәл сөйләгәннәрдән)



Лагерь дөньяның җәннәткә тиң бер почмагына — Кара диңгез буена, Аюдаг итәгенә урнашкан.



Биредә ел әйләнәсе — кояш, яшеллек, диңгез...


“Артек” балачакның иң гүзәл бер хатирәсе булып күңелдә саклана.





**Артектагы ал учаклар-**
**Дуслык, шатлык учаклары.**
**Учактай гел балкып торыр**
**Балачакның бу чаклары.**
**Ал учаклар якты өсти**
**Безнең изге теләкләргә.**



**“Артек”тагы учаклардан**
**Ут алабыз йөрәкләргә.**
**Очкыннарын сүндермичә**
**Ялкын итеп үрләтербез.**
**Шул ялкынны учак итеп**
**Өр-яңадан дөрләтербез!**

# “Ә мин “Орлёнок” пионер лагеренда ял иттем ...

**Әле ул елларда 1960 елның 12 июлендә ачылган Бөтенсоюз пионер лагере “Орленок” турында ишетеп кенә белә идек. Үсмер елларымдагы иң истәлекле көннәремнең берсе “Орленок” лагеренда ял итү бәхетенә ирешү булгандыр инде.”**

Әнә шулай зур горурлык хисләре белән сөйләде безгә Алексеевск районы Урта Тигәнәле авылында туып (1952), шул ук авылның урта мәктәбендә белем алган, хәзерге вакытта ( 1971 елдан бирле ) Урманасты Шынталы авылында яшәүче, мәктәптә директор булып эшләүче Әхмәтҗанова (Баязитова) Җөвәйрә Зөлкәфил кызы.

## «Орлёнок» истәлекләре

Баязитова (Әхмәтҗанова) Җөвәйрә Зөлкәфил кызының шәхси архивыннан алынды

!Мин үзем 60 нчы еллар баласы. Бу еллар укучыларда әдәп, әхлак тәрбияләү эшен балалар оешмаларын тагын да ныграк активлаштыру, аңа таяну аша алып барылган еллар. Минем дә башлангыч классларда укып йөргәндә ничек октябрят булуым, 3 нче класста ничек тантаналы рәвештә пионерлар сафына кабул ителүем, аннан инде , тагын да зурая төшкәч, ничек комсомолга керүем – барысы да бүгенгедәй хәтеремдә.

Безнең дружина Советлар Союзы Герое Зоя Космодемьянская исемен йөртә иде. Дружина составына кергән отрядлар, берсеннән-берсе уздырырга тырышып, отрядның исемен сайлый. Яраткан җырны сайлау да, үзеңнең девизыңны булдыру өстендә эшләү дә һәр отряд советы членыннан зур җаваплылык сорый. Отряд нинди атаклы кеше исемен йөртсә, шуның биографиясен бик ныклап өйрәнеп, аның батырлыгы турында сборлар үткәрә идек.

Менә шушы бер караганда бик гади генә булып күренгән хезмәтләребез аша бездә, ягъни укучыларда Бөек Ватан сугышы геройлары үрнәгендә туган илебезгә мәхәббәт , аның белән чынлап торып горурлану, әдәп, әхлак хисләре тәрбияләнгән икән.

Ул еллар мәктәпләрдә тимурчылык эшенең киң җәелгән чагы. Классыбыз белән чиратлашып,беркем мәҗбүр итмәүгә карамастан, бер риясыз балалар ялгыз калган карт-карчыкларга бик теләп булыша идек. Аларның куанычлары, безгә әйткән рәхмәт сүзләре әле хәзер дә ул елларның матур хатирәсе булып, сагындырып искә төшә.


Әйе, мәктәп еллары инде бик еракта калдылар. Еллар гына түгел, чорлар да алышынды, буыннар үзгәрде, дөньялар чуалды.Үзебез дә инде хәзер олы яшьтә. Гомеремнең күп өлеше балалар укыту һәм тәрбияләүгә багышланганга күрә, еш кына безнең чор балаларындагы миһербанлылык, кешелеклелек хисләре, еллар үткән саен, ни өчен юкка чыга бара икән , кем, кайчан, кайда ялгышлык җибәрде икән дип бик борчылам. Ә бит ныклабрак фикерли башласаң, бу тискәре күренешләрнең сәбәпләре илебездәге балалар оешмалары бетерелү белән бәйле түгелме икән дип тә уйлап куясың.

Без ул елларда укытучыларны гына түгел, өлкән пинервожатыебыз Зөләйха апаны да фәрештәгә тиңләп, һәр әйтәсе сүзен күз карашыннан аңлый идек. Билгеле, мин бераз активрак та булганмындыр инде. Җәмәгать эшләрендә дә һәрвакыт башлап йөререгә туры килде. Бәлки шуңадыр дружина советы председателе итеп сайлап куйдылар. Ул елларда укуда зур тырышлык күрсәткән укучыларны пионер лагерьларына җибәрә иделәр. Мин һәр җәйдә үзебездән ерак түгел урнашкан пионер лагеренда ял иттем.

Әле 1960 елда ачылган Бөтенсоюз пионер лагере “Орленок” турында ишетеп кенә белә идек. Мин үсмер елларымдагы иң истәлекле көннәремнең берсе шул лагерьда ял итү бәхетенә ирешү булгандыр инде. Авылдан ары китеп, хәтта район үзәгендә дә рәтләп йөрмәгән 7 класс укучысының бер төркем пионерлар белән поездга утырып, Кара диңгез буена ял итәргә җибәрелүе хөкүмәтебезнең ул чорда балаларга зур хөрмәте, аларның киләчәге турында нык кайгыртучанлык күрсәтүенең ачык мисалы булып тора дип саныйм мин.

Бөтенсоюз пионер лагере“Орленок” истәлекләрен сезгә дә тәкъдим итәм





17/IX. 66 год.


„Орленок" - комсомольский 3 отряд.

I. Толя Федоров, Коля Мельников, Батуев Женя, Костя Гордиенко, Веня Михайлов, Алексюк Саша, Хора Саша, Огородников Серёжа, Ситдиков Шаймардан, Вольнодворский Олег, Яна Тосконнова, Веня Зарецкий.

II. Леонтьева Люда, Чеусова Люся, Стаярова Галя, Верина Лена, Евдокименко Надя, Марышева Таня, Козлова Рита, Ротнюк Фая, Трунова Люда, Зайкова Люда, Саша Болмасова, Люда Смирнова, Валиятова Зубайра, Вера Барц, Таня Мойлянова, Чурикова Лиля, Нина Хайруллина, Таня Голубцова, Таня Круглова, Галя Минова, Галя Тарасова.

III. Баланов Юрий, Карпушкин Валера, Молоднин Слава, Рамиль Гимиатуллов, Толя Байбисов, Черепанов Коля, Кривошеев Сергей, Лысенко Олег, Игорь Пеарков, Бургард Гриша


Безнең отрядта 45 укучы иде. Күптөрле милләт балалары булуга карамастан, дус һәм тату идек. Әле бүгенге көндә дә хатлар аша аралашып, якын итешеп яшибез. Ял иткән көннәр истәлеген гел искә төшереп, яшүсмер елларга кайтып алабыз.



40 көн сизелми дә үтеп китте. Сентябрь ае булуга карамастан, Кара диңгез суы җылы, көннәр матур иде. Көнгә икешәр тапкыр тозлы суда рәхәтләнеп коена идек.



Без көн саен ял итеп, тауларга үрмәләп, төрле экскурсияләрдә генә булмадык, атнага 3 тапкыр менә шушы мәктәпкә укырга йөрдек . Чөнки алган белемнәр онытылырга тиеш түгел, өйгә кайткач, иптәшләреңә ияреп китәргә кирәклекне аңлый идек. Билгеле, бу мәктәп авыл мәктәбеннән бикнык аерыла. Үзе зур, якты, җылы.Үземне бөтенләй икенче дөньяда итеп хис итә идем.



Көн саен дружина сборы үтә иде. Анда отрядлар үткән көн турында рапорт бирәләр. Бу эшкә һәр отряд бик җаваплы карап, ничек тә көнне матур, кызыклы, нәтиҗәле итеп үткәрергә тырыша иде.

Җөвәйрә апа безгә “Орленок” пионерлагерена багышланган “Звездопад” җырын җырлап күрсәтте:

*С неба лиловые падают звёзды,*
*Даже желанье придумать не просто…*
*На небосклоне привычных квартир*
*Пусть загорится звезда Альтаир.*

*Припев.*
*Звездопад, звездопад…*
*Это к счастью, друзья, говорят…*
*Мы оставим на память в палатках*
*Эту песню для новых орлят.*

*Что пожелать вам, мальчишки, девчонки?*
*Встретиться снова бы в нашем «Орлёнке»!*
*Будет и солнце, и пенный прибой,*
*Только не будет смены такой…*
*Припев.*

*Как бесконечные звёздные дали,*
*Мы бы на яркость людей проверяли.*
*Прав лишь горящий, презревший покой,*
*К людям летящий яркой звездой*
*Припев*

*Пусть перед нами дороги земные,*
*Слышим мы дальних миров позывные.*
*Юность и песню, и крылья дала*
*Тем, кто поверил в созвездье Орла.*
*Припев.*

## Юрий Алексеевич Гагарин исемендәге пионер оешмасының дружина сборы

**3 нче сыйныф укучыларын пионер сафларына кабул итү**
(истәлекләр)
1986 е













1986 ел 22 нче апрель. IV нче класс укучыларын пионер сафларына кабул итү. Тантаналы вакыт.



Айга бер тапкыр актив укуы алып барыла иде. Аны дружина советы председателе җитәкли иде.



1986 ел. Дружина советы председателе Вәлиева Эльза

# Урманасты Шынталысы мәктәбенең пионер отрядлары

(әби-бабайларның, әти-әниләрнең, укытучыларның шәхси архивыннан истәлекләр)



1962 нче еллар. Пионерлар һәм комсомоллар



Әлеге фотода 1949 нчы елда туучылар. Ахметзянов Альберт, Ислямова Мәрьям апалар сыйныфы. Укытучы - Х. Гөлсимә апа.



Сыйныф җитәкчесе Махмутов Наил



1955 нче елда туучылар.
Класс җитәкчесеХуснутдинова Хава апа белән.



Әлеге фотода 1960 нчы елда туучылар. Нургатина (Вафина) Дилә, Давлетшин Халимнар сыйныфы. Сыйныф җитәкчесе Махмутова Заһирә



1962 нче елда туучылар. Сыйныф җитәкчесе Ахметзянова Җ.



1964 нче елда туучылар. Сыйныф  җитәкчесе Ишниязова Рабига



1970 елда туучылар. Сыйныф җитәкчесе Ишниязова Рабига



1986 ел. 6 нчы сыйныф укучылары.
**Володя Дубинин исемендәге отряд. Отряд советы председателе – Ислямова Румия.**
Арттагы рәттә сулдан уңга: Ислямова Румия, Ишниязова Ләлә, Вәлиева Эльза, Билалов Радик.
Беренче рәттә: Ахметзянов Айдар, Гимадиев Илнур, Вәлиев Рәмис, Ишниязов Илназ.



1975 нче елда туучылар. Сыйныф җитәкчесе Ишниязова Сирень



1976 нчы елда туучылар. Сыйныф җитәкчесе Миндубаева Н.Х.



1977 нче елда туучылар. Сыйныф җитәкчесе Миннеханов М.



Пионер оешмасы тарихын эзләнү, өйрәнү барышында пионерлар тормышы турында күп яңалык белдек, күңелләребездә алар белән горурлану, туган илнең лаеклы шәхесләре булып үсү теләге уянды.

Әйе, пионерлар хәрәкәте белән бәйле булган һәркемнең күңелендә чиксез күп якты хатирәләр сакланган, тормышларында онытылмас эз калган.

Без туплаган әлеге материал укучыларга Урманасты Шынталысы пионер оешмасы тарихы белән тирәнрәк танышу мөмкинлеге бирә.

Республикабызда хәзерге чорда да балалар хәрәкәте көчәйгәннән-көчәя бара. Мәктәбебезнең пионер оешмасы күп еллар буе Юрий Алексеевич Гагарин исемен йөрткән. Татарстан варис - пионерлар берлеге оешканнан соң, бу оешманың методлары буенча, мәктәбебез варис пионерлар оешмасы - "КОЯШ" дип атала башлаган. Ул Кыю Омтылыш Яшәү Шартыбыз дип таркатыла.

Девизыбыз: Һәркөнне игелекле эш эшлә!

Балалар хәрәкәтенең эшчәнлеген үз вакытында беренче президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиев та хуплап: “Без республикабызның киләчәген сезнең белән, сезнең хезмәт итә, дус була белүегез, традицияләрне саклый, ихтирам итә һәм үстерә белүегез белән бәйләп карыйбыз.

Балалар хәрәкәте тарихы безнең халыкның тарихыннан аерылгысыз һәм ул балалар оешмаларының югарыдан көчләп тагылган түгел, ә яшьләргә органик рәвештә хас булган оешма булуы турындагы фикерне бик ачык раслый”,- дип белдергән иде ул Татарстан варислары берлегенә котлавында.

Без, әлбәттә, үзебезнең Татарстан варислары берлеге әгъзасы булуыбыз белән чиксез горурланабыз. Киләчәктә дә балалар оешмаларының янып, гөрләп яшәвен телибез.

“Балалар оешмасы элек һәм бүген”

- Күңеллерәк булган, оешканрак, әле бит быргы белән барабан үзе генә ни торган.
- Миңа хәзер дә күңелсез түгел. Безнең “КОЯШ” оешмасында күңелсезләнеп утырырга вакыт бармы?
    - Темага якынрак килик. Кем ул пионер?
    - Советлар Союзы Коммунистлар партиясе эше өчен һәрвакыт әзер булган кеше!
    - Үз заманының чын герое.

- Кем ул варис?
- Һәрвакыт игелек кылырга әзер бул!
- Һәрвакыт әзер!
- Аерма күренми.
- Отряд, дружина сборлары...
- Чиреккә бер дружина сборы, оешма утырышлары.
- План, карар, эшкә анализ – аерма зур түгел.
- Бөтенсоюз слетлары.
- Әйе, слетлар күренми, әмма балалар Думасы бу эшнең уңышлы башлангычы булыр дип уйлыйм.
- Тимур һәм аның командасы!
- Валантерлар, Хәйрия елы, ярдәмгә мохтаж олыларга булышу – безнең дә төп эшебезнең берсе.
- Макулатура, металлолом, икенче чимал җыю.
- "Җиребезне чүп-чардан чистартыйк!" акциясе!
- Карагыз әле, бер уйлаганда, аерма бик зур түгел!

- **"КОЯШ" нәрсә аңлата?**
- Яшәү рәвеше.
- Сәламәт яшәү рәвешен сайлаган кебек, без "КОЯШ" оешмасын сайлыйбыз!

- **"КОЯШ" безгә нәрсә бирә?**
- Файдалы, күңелле, онытылмаслык яшәү рәвеше!
- Мөстәкыйльлек.
- Фикер киңлеге.
- Иҗадилык.
- Елмаю,
- яхшы кәеф,
- яңа дуслар...

- **"КОЯШ" безне нәрсәгә өйрәтә?**
- Сау-сәламәт
- Зыялы
- Кешелекле
- Рухи зәвыклы
- Югары әхлаклы
- Туган ягыбызның табигатен
- Халкыбызның тарихи мирасын саклаучы
- Туган республикабызның, илебезнең лаеклы гражданины булырга!

**"КОЯШ" - ул безнең дөнья!**
**Таң булып атарбыз,**
**Кояш булып балкырбыз!**